ПӘНҖЕШӘМБЕ
8 ФЕВРАЛЬ
1940 ел
№ 31 (5831)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

ФИНЛАНДНЫ ҮТӘҮ— МАКТАУЛЫ БУРЫЧ

Узган 1939 нчы ел, Сталинчыл өченче бишьеллыкның икенче елы халык хуҗалыгын алга җибәрүдә, үстерүдә, халкыбызның материал көнкүреш-тормыш шартларын яхшыртуда гаять зур казанышлар китерде. Дәүләт промышленносты предприятиеләре продукция эшләп чыгаруны, 1938 нче елга караганда, 14,7 процент, промысло кооперацияләре 21 процент үстерделәр. Товар әйләнеше планы 16,7 процент артты. Дәүләт бюджеты арттырып үтәлде. Планнан тыш 4 миллиард 100 миллион сум мая тупланды.

Бу гүзәл йомгаклар халык хуҗалыгының барлык тармаклары буенча да зур үсеш барлыгын, халык массасының иҗади инициативасының нык үсүен, совет кешеләрендә бөек патриотизм хисләренең көчле булуын ачык чагылдыралар.

Сталинчыл өченче бишьеллыкның өченче елына—1940 нчы елга илебез әнә шундый зур казанышлар белән керде. Бу өлкәдә совет финансы, совет бюджеты зур роль уйнады һәм уйный. Чөнки ул халык хуҗалыгын әледән әле үстерү, алга җибәрү өчен хезмәт итә. Безнең социалистик дәүләт бюджеты—ул бөтен халык бюджеты.

1940 нчы ел илебезнең финанс куәтен тагын да ныгыту һәм үстерү елы булырга тиеш. Бюджетыбызның туктаусыз рәвештә үсә баруы финанс системасының хуҗалыгыбыз белән элемтәсен тагын да ныгытуны, финанс органнарының промышленностька һәм сәүдә челтәренә тагын да ныграк йогынты ясауларын катылык белән таләп итә. Финанс планын тайпылышсыз рәвештә тормышка ашыру, социалистик хуҗалыгыбызның рентабельле эшләвен тәэмин итү—финанс работниклары алдында торган җаваплы һәм мактаулы бурычлар әнә шундый.

Узган елны республикабызның финанс органнары, 1938 нче елга караганда, яхшырак эшләделәр. Дәүләт доходлары буенча еллык планның 100,9 процент, налог түләүләре планы 102,3 процент, страховой түләүләре 106 процент, шул исәптән ирекле страхование түләүләре буенча 139,6 процент итеп үтәлүе моның ачык күрсәткече.

Чепья, Азнакай, Калинин, Апас, Мөслим, Тымытык районнары аеруча яхшы эшләделәр һәм эшлиләр. Алар финанс планын кварталдан кварталга арттырып үтәделәр һәм бу казанышларын 1940 нчы елда да ныгыталар. Җиңүнең сере нәрсәдә соң? Аның сере—финанс планын үтәү өчен большевикларча көрәшүдә, финанс активистларына оператив җитәкчелек итүдә, масса арасында политик-масса эшләрен үрнәк итеп оештыруда.

Мисаль өчен финанс эше буенча республикабызның иң алдынгы Тымытык (райфо мөдире иптәш Кәримев) районын алыйк. Ул Татарстан Совнаркомының күчмә кызыл байрагын үз кулында нык тота. Монда финанс эше буенча 400 дән артык активист бар, алар хөкүмәтебезнең һәм партиябезнең бюджет-налог политикасын массага аңлатуны үрнәк булырлык итеп оештырганнар. Финанс активы масса белән көндәлек элемтә булдырган. Мондый мисальләрне Чепья районы (райфо мөдире иптәш Гарифҗанов) буенча да күп кенә күрсәтергә мөмкин.

Шулай да, безне бу уңышлар гына канәгатьләндерә алмыйлар әле. Финанс эшен кискен рәвештә тагын да яхшырту өчен бездә мөмкинлекләр гаять зур. Тик бу мөмкинлекләрдән файдалана белергә, барлык районнарның да үрнәк эшләүләренә ирешергә кирәк.

Республикабызның барлык районнары да бу таләпне үтиләр дип әйтеп буламы соң? Кызганычка каршы, моны әйтеп булмый әле. Югары Ослан, Столбище, Тәтеш, Тәмте, Красный Бор, Куйбышев, Тельман, Алабуга кебек районнар хурлыклы рәвештә койрыкта сөйрәләләр. Алар финанс планын 1939 нчы елда үтәмәгән кебек, быел да артта калгалар. Бу районнарда партия һәм совет оешмаларының җитәкчеләре финанс эшенә игтибар биреп җиткермиләр. Бу эш тирәсенә масса активлыгын тупламыйлар.

Татарстан Наркомфинының налоглар бүлеге (начальнигы иптәш Шилов) һәм саклык кассалары идарәсе (управляющие иптәш Калугина) турында да шуны ук әйтергә мөмкин. Чөнки бу бүлекләрнең дистәләрчә работниклары урыннарда өзлексез рәвештә булып торуларына карамастан, булган кимчелекләрне теркәү белән генә чикләнәләр. Ә ул кимчелекләрне бетерү буенча урындагы работникларга җитәрлек ярдәм күрсәтмиләр.

1940 нчы ел бурычлары финанс эшенә партия һәм совет оешмаларының, бөтен совет җәмагатьчелегенең игтибарын кискен рәвештә көчәйтүне таләп итәләр. Быел финанс эшенең барлык тармаклары буенча 1,5 миллиард сум акча җыелырга тиеш. Моны үтәү эшен намус белән башкару, 1940 нчы елга билгеләнгән 400 миллион сумнан артык бюджетны тайпылышсыз үтәү—республикабызның барлык хезмәт ияләренең изге бурычы.

Кичә Татарстан финанс активистларының республика киңәшмәсе үзенең эшен тәмамлады. Бу киңәшмә 1939 нчы ел йомгакларын һәм 1940 нчы ел бурычларын тикшергәннән соң, орденлы республикабызның данлыклы XX еллыгы исемендәге социалистик ярышка зур күтәренкелек белән кушылганлыгын белдерде. Киңәшмә, Башкыртстан республикасы белән социалистик ярышка чыгу турында карар кабул итте һәм ярышның төп күрсәткечләрен билгеләде:

Финанс планын һәрбер район, шәһәр һәм авыл буенча срогыннан элек үтәүне тәэмин итәргә, бюджет буенча билгеләнгән барлык чараларны үз вактында үтәргә һәм аннан тулысынча файдаланырга, дәүләт средстволарын саклык белән тотарга, һичбер төрле законсызлыкка юл куймаска. 1940 нчы елның финанс планын иң яхшы күрсәткечләр белән вактыннан элек үтәү өчен көрәшкә барлык финанс работникларын, шулай ук бюджет комиссияләре һәм комсодлар тирәсенә күп санлы финанс активистларын тартырга, аларның үзара ярышып эшләүләренә ирешергә.

Бурыч, социалистик йөкләмәләрнең тулысынча үтәлүенә ирешүдән, социалистик ярышка һәрбер финанс работнигының кушылуын тәэмин итүдән, бу хәрәкәткә массаның зур активлыгын туплаудан, артта калучыларга практик ярдәм күрсәтүдән, аларга алдынгыларның бай тәҗрибәләрен күчерүдән гыйбарәт.

Финанс эшенең яңа күтәрелеше өчен! 1940 нчы ел финанс планын тулы һәм арттырып үтәү өчен көрәштә Башкыртстан белән ярышта алдынгылыкны яулап алыйк! Орденлы республикабызның XX еллыгын зур уңышлар белән каршылыйк!

Финанс работникларының республика киңәшмәсе

Финанс работникларының 5 нче февральдә ачылган республика киңәшмәсе кичә үзенең эшен тәмам итте. 1939 нчы ел йомгаклары һәм 1940 нчы ел бурычлары турында нарком иптәш Шәрәфиев докладына буенча фикер алышуларда 25 кеше катнашты.

Фикер алышуларда катнашучылар финанс органнарында үтәлешне тикшерүнең җитәрлек булмавын, налог законнарын бозу фактлары булуын, налог агентлары һәм инспекторлар белән эшләүнең җитәрлек булмавын күрсәттеләр.

Киңәшмәдә икенче мәсьәлә итеп орденлы Башкыртстан республикасы белән орденлы Татарстан республикасы финанс работникларының 1940 нчы ел өчен төзелгән социалистик ярыш договоры тикшерелде һәм аңа кул куелды. Соңыннан Татарстанның барлык финанс работникларына һәм финанс активистларына мөраҗәгать кабул ителде.

Наркомфин, киңәшмәдә катнашучы иң алдынгы финанс работникларыннан 40 кешене бүләкләде. Бүләкләнүчеләр арасында Тымытык районы финанс бүлеге мөдире Кәримов, Чепья районы финанс бүлеге мөдире Гарифҗанов, Азнакай районы финанс бүлеге мөдире Фазлиев, Калинин районы финанс бүлеге мөдире Бакиров һәм Әтнә районы, Югары Көек авылы налог агенты Җәләева, Апас районы налог агенты Фомин һ. б. иптәшләр бар.



ЛЕНИН ШӘҺӘРЕНЕҢ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫ ӨЧЕН, ВАТАН ӨЧЕН, БӨЕК СТАЛИН ӨЧЕН!
Художник В. Корецкий эшләгән плакат.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ НАЧАЛЬНИКЛАРЫ СОСТАВЫНА СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ ИСМЕ БИРҮ ТУРЫНДА

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул вакытта батырлык һәм геройлык күрсәткән өчен **Ленин** ордены һәм **„Алтын Йолдыз“** медале белән берлектә **Советлар Союзы Герое** исме бирергә:

1. Лейтенант Иван Михайлович **Беловка.**

2. Политрук Владимир Дмитриевич **Капустинга.**

3. Өлкән политрук Степан Ефремович **Пономарчукка.**

4. Кече командир Павел Федорович **Поросенковка.**

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе
М. КАЛИНИН.

СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре
А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
5 февраль, 1940 ел.

Кызыл Армиянең начальниклар һәм рядовойлар составын СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләү

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул вакытта батырлык һәм кыюлык күрсәткән өчен СССР Верховный Советы Президиумының указы белән Кызыл Армиянең начальниклар һәм рядовойлар составыннан 248 кеше СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләнделәр.

Ленин ордены белән 14 кеше бүләкләнде: кызыл армеец **В. А. Алексеенко,** кече лейтенант **М. Н. Анохин,** лейтенант **М. К. Антонюк,** капитан **Д. Д. Валентик,** полковник **А. В. Ворсин,** кече лейтенант **К. И. Головкин,** кече лейтенант **И. Е. Дворецкий,** лейтенант **А. П. Зеленов,** кече командир **Н. Я. Калинин,** кече лейтенант **П. И. Киров,** кызыл армеец **И. К. Корбаков,** политрук **М. А. Петяхин,** кече лейтенант **И. И. Сапрыкин,** өлкән лейтенант **И. В. Сукманов.**

„Кызыл Байрак“ ордены белән 69 кеше бүләкләнде. Алар арасында полковник **А. И. Акимов,** кече политрук **С. Ф. Басов,** кызыл армеец **А. А. Брусницов,** майор **К. П. Колесников,** кызыл армеец **А. П. Корзиков,** өлкән лейтенант **В. В. Котов,** лейтенант **С. Д. Ларин,** кызыл армеец **В. А. Малков,** өлкән лейтенант **А. П. Михин,** кызыл армеец **Н. П. Паныгин,** лейтенант **А. А. Прокофьев,** кече политрук **К. Г. Соломонов,** кызыл армеец **П. Д. Тюков,** лейтенант **Е. А. Фомин,** капитан **И. Н. Цепляев,** кече лейтенант **А. В. Чисков,** капитан **П. З. Шевелев,** комбриг **В. И. Щербаков** һәм башкалар бар.

„Кызыл Йолдыз“ ордены белән 46 кеше бүләкләнде. Алар арасында кызыл армеец **А. А. Аветьян,** өлкән политрук **И. Ф. Белыгин,** батальонный комиссар **В. П. Беркутов,** кызыл армеец **Д. К. Бровченко,** өченче ранг хәрби инженер **П. П. Гольцев,** полковник **А. А. Гусаков,** бригвоенюрист **П. А. Дмитриев,** дәүләт куркынычсызлыгы өлкән лейтенанты **Д. Е. Камбург,** кече лейтенант **А. К. Лосев,** полковник **П. Д. Мирошников,** икенче ранг хәрби врач **И. И. Образцов,** кызыл армеец **А. Н. Фомичев** һәм башкалар бар.

„Батырлык өчен“ медале белән 68 кеше, **„Хәрби хезмәтләре өчен“** медале белән 51 кеше бүләкләнде.

(ТАСС).

ССР СОЮЗЫ ОРДЕННАРЫ ҺӘМ МЕДАЛЬЛӘРЕ ТАПШЫРУ

5 нче февральдә СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш М. И. Калинин бүләкләнгән кешеләргә орденнар һәм медальләр тапшырды.

„Георгий Седов“ бозваткыч пароходын Арктика бозларыннан чыгару буенча хөкүмәт экспедициясе начальнигы Советлар Союзы Герое иптәш И. Д. Папанинга икенче „Алтын Йолдыз“ медале бирелә. Бу медаль аңа хөкүмәт заданиесен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул эштә аңа Советлар Союзы Герое исме алырга хокук бирә торган геройлык күрсәткән өчен бирелде.

Авыл хуҗалыгында күренекле булырлык уңышлар өчен һәм төп авыл хуҗалыгы эшләре планын, бигрәк тә мамыкчылык һәм терлекчелек планнарын арттырып үтәгән өчен Төрекмәнстан ССР колхозчыларының, партия һәм совет работникларының зур группасына бүләкләр бирелә.

Бүләкләнүчеләр исменнән Каралак Торе һәм Ходайбиргәнев Аетбай иптәшләр партиягә, хөкүмәткә һәм бөек Сталинга чын күңелдән рәхмәт һәм бирелгәнлек белән тулы булган речьләр сөйләделәр.

Иптәш М. И. Калинин бүләкләнүчеләрне котлады һәм аларга яңа уңышлар теләде. (ТАСС).

СЕДОВЧЫЛАР МОСКВАДА

Союзлар Йортының колонналы залында очрашу

5 нче февральдә Союзлар Йортының Колонналы залында Төньяк Диңгез Юлы Баш идарәсе работниклары һәм башкаладагы оешмаларның вәкилләре „Георгий Седов“ бозваткыч пароходының данлыклы экипажы белән очраштылар.

Советлар Союзы Герое иптәш П. П. Ширшовның такдиме буенча почетлы президиумга көчле кул чабулар астында иптәш Сталин җитәкчелегендә ВКП(б) Үзәк Комитеты политбюросы һәм иптәш Димитров сайланалар.

„Седов“ бозваткычының капитаны Советлар Союзы Герое иптәш Бадигин, Советлар Союзы Герое иптәш Трофимов һәм Советлар Союзы Герое иптәш Буйницкий көчле кул чабулар белән каршы алыналар.

Ике тапкыр Советлар Союзы Герое Иван Дмитриевич Папанинның трибунада күренүе көчле кул чабулар белән каршы алына. Аның образлы һәм ачык рече седовчыларның батырлыгына,—Ватаныбыз өчен, алдынгы совет фәне өчен, бөек Сталин өчен эшләнгән батырлыкка багышланган иде.

Кабул итүдә җыелучылар зур күтәренкелек белән Сталин һәм Молотов иптәшләргә котлау кабул иттеләр. (ТАСС).

Чит илләрдә

БАЛКАН АНТАНТАСЫНЫҢ ДАИМИ СОВЕТ СЕССИЯСЕНЕҢ ЭШ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДА БЕЛДЕРҮ

БЕРЛИН, 5 февраль. (ТАСС). Белградтан хәбәр итүләренә караганда, Балкан Антантасы советы председателе Гафенку сессия тәмам булганнан соң түбәндәге рәсми белдерүне иглан иткән:

„Даими совет членнары арасында чын күңелдән һәм ышаныч шартларында барган фикер алышулар түбәндәгеләрне бердәм рәвештә күрсәтергә мөмкинлек бирделәр:

1. 4 илнең дә көньяк-көнчыгыш Европада тынычлык, тәртип һәм куркынычсызлык саклауга гомуми омтылуы.

2. Европаның бу өлешен сугыштан саклап калу өчен кискен тынычлык политикасын дәвам иттерергә һәм хәзерге сугышка карата үзләренең позициясен саклап калырга ныклы теләк.

3. Үзенең максатлары булган һәм бер кемгә каршы да юнәлдерелмәгән Антанта составында Балкан Антантасы членнарының берләшкән хәлдә калырга ныклы омтылышлары: Антантаның һәрбер членының хокукларын, аларның бәйсезлеген һәм милли территорияләрен саклауны бергәләп күзәтү.

4. Күрше дәүләтләр белән тынычлыкны саклау, үзара аңлашу һәм тыныч рәвештә бергәләп эш итү рухында дуслык мөнәсәбәтләре тотарга һәм аларны киңәйтергә чын күңелдән теләк.

5. Балкан дәүләтләре арасында экономик элемтәләрне ныгыту һәм яхшырту, Балкан Антантасында торучы илләр арасында сәүдә алмашуын киңәйтү кирәклеге.

6. Балкан пактын яңа устав чорына—1940 нчы елның 9 нчы февраленнән башлап 7 елга озайту.

7. Даими советның алдагы чираттагы сессиясен 1941 нче елның февралендә Афина шәһәрендә чакырырга“.

МАННЕРГЕЙМ БАНДАЛАРЫНА КАРШЫ ШВЕЦИЯ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕНЕҢ ХӘРӘКӘТЕ

СТОКҺОЛЬМ, 5 февраль. (ТАСС). Швециядә чыга торган „Ню даг“ газетасы Швециянең ак Финляндия белән чиктәш булган авылларында яшәүчеләрнең настроениеләре турында мәкалә басып чыгарды.

Газета болай дип яза:

„Норрботтен (Швециянең Финляндия белән чиктәш өлкәсе) хезмәт ияләре Маннергейм Финляндиясенә карата чиктән тыш каршы настроениедә. Норрботтен халкы ак финнәрнең 1918 нче елны хезмәт иясе фин халкына каршы канлы походын, 1931 нче елны лапуас палачларының погромнарын, ак Финляндиядә шведларның күп еллар буена эзәрлекләнүләрен яхшы хәтерлиләр. Алар шулай ук ак финнәрнең үзләренең басып алу планнарына Советлар Карелиясен һәм төньяк Норвегияне генә түгел, бәлки бөтен Норрбаттен өлкәсен кертканлекләрен дә онытмыйлар.

Швециянең чиктәш авылларында Маннергейм режимын яхшы беләләр. Нинди булса да социал-демократ „юлбашчы“ларның берсе ак финнәргә ярдәм итәргә чакырганда швед крестьяннәре һәм эшчеләре аңа: „Ялганлама, без Маннергейм Финляндиясенә бик якын торабыз һәм Финляндия хезмәт ияләре өчен аның нинди җәһәннәм икәнлеген беләбез“ дип җавап бирәләр.

Ак фин сугыш чукмарларының чигенгән вакытта авылларны һәм шәһәрләрне яндырулары, терлекләрне үтерүләре һәм тыныч халыкны туган җирләреннән көчләп куып алып китүләре турында ишеткәч бу өлкәдәге хезмәт иясе халыкның маннергеймчы хиянәтчеләргә карата дошманлыгы аеруча көчәйде. Чик буендагы Торнео елгасының теге ягында халык армиясенең тәртип урнаштыру көнен Норрботтен халкы тынычлык һәм ышаныч белән көтә. Норрботтен халкы үзенең яңа күршесен—Куусинен җитәкчелегендәге Финляндия демократик республикасын шатланып алкышлар“.

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 5 февраль. Сугыш хәрәкәтләре турында кичә кич Парижда иглан ителгән белдерүдә болай диелә: „Иртә белән дошманның разведка отрядлары белән көчле бәрелешләр булды“.

Бүгенге иртәнге белдерүдә „Фронтта бер нинди яңалык булмады“ диелә.

БЕРЛИН, 6 февраль. Германиянең информация бюросы сугыш хәрәкәтләре турында түбәндәге белдерүне тапшыра:

„Көнбатыш фронтта әйтерлек вакыйгалар булмады. Бейсенбургтан көнчыгыштарак Лаутер елгасы аркылы чыгарга маташкан француз разведкасы отрядларының һөҗүме кире кагылды. Швейгеннан көньяк - көнчыгыштарак булган сугыш вактында Германиянең разведка дозоры ике кешесен сугыш кырында калдырды. Алар, җиргә күмелгән кул гранаталарының шартлавы һәм артиллерия атышуы аркасында авыр яраланганнар.

1940 нчы елның 21 нче январеннан 31 нче январена кадәр Германия авиациясе гомуми авырлыгы 36.000 тонна булган дошман корабларын батырды. Исемнәре билгесез булган күп санлы батырылган кораблар болар исәбенә керми. Соңгыларын исәпләгәндә, дошманның 10 көн эчендә югалткан корабларының гомуми авырлыгы 47—48 мең тоннага җитә“.

(ТАСС).

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

Көньяк Кытайда

Гуанси провинциясенең көньяк өлешендә, Наньниннан 60 километр көнчыгыштарак, моннан берничә көн элек японнар бу пункттан төньяктарак урнашкан кытай позицияләренә каршы һөҗүм башлаганнар иде. Кытай гаскәрләре белән япон гаскәрләре арасында каты сугыш башланды һәм ул 3 көн дәвам итте. Кытай гаскәрләре японнарга ныклы каршылык күрсәттеләр.

Төньяк Кытайда

Суйюань провинциясенең көнбатыш өлешендә, Баотоудан көнбатыштарак булган районда японнар колоннасы кытайларның оборона линиясен өзеп Уюаньга һөҗүмне дәвам иттерә. Кытай гаскәрләре бу колоннаның тыл белән элемтәсен өзделәр.

Сентраль Ньюс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, японнарның Баотоудан Уюаньга барганда 350 дән артык кешеләре үтерелгән. Японнар 37 йөк автомобилен ташлап калдырырга мәҗбүр булганнар. Соңыннан бу автомобильләрне кытайлар алганнар.

Шаньси провинциясенең көньяк көнчыгыш өлешендә, Чжанцзы, Луань һәм Хугуань районнарында тынлык. Сентраль Ньюс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, соңгы вакытта бу районнарда булган сугышларда японнарның 20 мең солдатыннан 7—8 мең кеше үтерелгән һәм яраланган.

Үзәк Кытайда

Хубэй провинциясенең төньяк өлешендә, Суйчжоу районында кытайлар 100 ләп винтовка кулга төшергәннәр һәм 20 резин көймәне яндырганнар.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

5 нче февральдә фронтта разведчикларның эзләнүләре һәм аерым участкыларда артиллериядән сирәк-сирәк атышу булды.

Ладуга күленнән төньяктарак булган районда пехота частьләренең бәрелешләре дәвам итте.

Безнең авиация разведка очышлары алып барды.

**

6 нчы февральдә фронтта разведчикларның эзләнүләре булды, Ладога күленнән төньякта вак пехота частьләренең бәрелешләре дәвам итте.

Безнең авиация разведка очышлары ясады.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

ПРОПАГАНДА ЭШЕ ТИЕШЛЕ ЮГАРЫЛЫКТА ТҮГЕЛ

Вахитов исемендәге жиркомбинатның алдынгы интеллигенциясе, партияле һәм партиясез большевиклары революцион теорияне үзлекләреннән өйрәнәләр.

Хезмәт бүлеге начальнигы Токарев, инженер Стракова иптәшләр „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнүне төгәлләгәннәр. Хәзер алар Маркс — Энгельс — Ленин — Сталин әсәрләрен өйрәнеп, үзләренең идея-политик дәрәҗәләрен күтәрү өстендә системалы рәвештә эшлиләр. Баш инженер Щербаков, инженер Константинов, Мифтахова һәм башка иптәшләр марксизм-ленинизм теориясен үзләштерүдә тырышып укыйлар.

Ләкин бездә большевизмны үзләштерүдә бу иптәшләрнең гүзәл тәҗрибәләрен башкалар белән уртаклашу, алар үрнәгендә башка иптәшләрне тәрбияләү эше һич канәгатьләнерлек түгел әле. Соңгы вакытта комбинатның партбюросы да бу мәсьәлә буенча бер нәрсә дә эшләгәне юк.

Сабын, шәм, стеарин заводлары һәм гидрозавод янындагы партоешмалар комбинатта иң зур оешмалардан саналалар. Ләкин аларда партия пропагандасының куелышы тиешле югарылыкта түгел. Бу оешмаларның җитәкчеләре учетта торучы коммунистлардан партия тарихын кемнәрнең ничек өйрәнүләре турында бер нәрсә дә белмиләр. Мәсәлән, гидрозавод парторгы иптәш Ефимовтан: сездә партия тарихын кемнәр яхшы өйрәнәләр? дип сорагач ул, смена инженеры иптәш Сабировны күрсәтә. Ләкин Сабиров „кыскача курс“ ның әле 2 нче бүлеген генә өйрәнә башлаган.

Сабын заводы начальнигы иптәш Саватьев, механика цехы начальнигы иптәш Гордеев һәм цех парторгы иптәш Александров IV нче бүлекне өйрәнә башлаганнар да, туктаганнар. Сабын заводы мастеры иптәш Хәйруллин һаман да 2 нче бүлекне „өйрәнә“, ә коммунист иптәш Усманов партия тарихын өйрәнүгә бөтенләй керешмәгән.

ВКП(б) тарихын өйрәнү буенча комбинатта оештырылган ике түгәрәк канәгатьләнерлек эшләми. Бу түгәрәкләрдә йөреш түбән, тыңлаучыларның күпчелеге занятиеләргә хәзерлексез киләләр. Занятиеләр еш кына өзеләләр.

Рус телен яхшы белмәүче һәм партия тарихын үзлекләреннән өйрәнергә хәзерлекләре җитмәүче иптәшләр, ВКП(б) тарихын татар телендә өйрәнү түгәрәге оештыруны партбюродан сораганнар иде. Ләкин партбюро бу иптәшләрнең теләкләрен шушы көнгә кадәр үтәгәне юк.

Г. Таҗиева.

ПРОПАГАНДИСТЛАРНЫҢ ӨЛКӘ СЕМИНАРЫ

ВКП(б) Өлкә Комитетының пропаганда бүлеге янында ВКП(б) райкомнарының штатлы пропагандистлары өчен системалы рәвештә семинарлар эшләп килә. 1939 нчы елны 5 семинар үткәрелде.

5 нче семинар 10 көн буена ВКП(б) Өлкә Комитетының партия мәгарифе йортында эшләде һәм үзенең эшен 17 нче январьда тәмам итте. Анда 220 кеше катнашты. Алар „кыскача курс“ның VII, VIII һәм IX нчы бүлекләрен урта звено буенча һәм VIII, IX һәм X нчы бүлекләрен түбәнге звено буенча өйрәнделәр.

Татар пропагандистлары өчен семинар занятиеләре һәм лекцияләр татар телендә алып барылды.

Семинарда лекцияләр уку һәм занятиеләр үткәрү өчен ВУЗ ларның укытучылары, ВКП(б) Өлкә Комитеты лекторлары тартылды һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты лекторлары Леонов һәм Белый иптәшләр чакырылды.

Семинарлар пропагандистларның теоретик яктан үсүләренә бик нык ярдәм итә. Беренче семинарларда кайбер иптәшләр занятиеләргә актив катнашмадылар. Соңгы семинарда исә занятиеләр аеруча җанлы һәм актив үтте. Чыгып сөйләүчеләр пропагандистларның семинарга яхшы хәзерләнеп килүләрен күрсәтте. Күп кенә иптәшләр үзләренең теоретик белемнәрен күтәрү өстендә тырышып эшлиләр. Болар исәбенә Бесчастнов, Корнилов, Семенов, Борисов, Киняшева, Закирова, Гобәев, Фәйзерахманова, Еникеев, Ушкварова һәм күп кенә башка иптәшләрне кертергә мөмкин.

Партиянең кайбер оешмалары, яхшы хәзерлекле пропагандистларның ныклы кадрлары турында җитәрлек кайгыртмыйлар, пропагандистларны башка эшләргә күчерәләр. Нәтиҗәдә, һәрбер семинарга, элекке семинарларда булмаган 20—25 яңа пропагандист килә. ВКП(б) ның кайбер райкомнары пропагандистларны семинарга вактында җибәрмиләр, монда Казан шәһәре райкомнарын аеруча күрсәтергә кирәк.

Кайбер райкомнар пропагандистларны семинарга җибәрмәү өчен төрле объектив сәбәпләр табалар. Мәсәлән, ВКП(б) ның Яңа Писмән райкомының парткабинет мөдире һәм пропагандисты иптәш Кафичева барлык семинарларда системалы рәвештә һәм актив катнашып килде. Ләкин ВКП(б) райкомы, ул әле күптән түгел генә Казанда бик озак торып кайтты, дигән сылтау белән, аны соңгы семинарга җибәрмәде.

Пропагандистларның чираттагы семинары март аенда үткәреләчәк. Бу семинарга хәзерләнгәндә моңа кадәр булган кимчелекләрне кискен рәвештә бетерергә кирәк.

Антонова.

ВКП(б) Өлкә Комитетының партия мәгарифе йорты мөдире.

Безгә райкомның булышлыгы йомшак

Чистай район мәгариф бүлеге янында моннан бер ел элек башлангыч партоешма оештырылган иде. Шушы чор эчендә партоешма нык кына үсте. ВКП(б) членлыгына кандидат итеп 8 кеше кабул итте. Оешманың яңа булуы, составының күпчелеге яшь коммунистлардан торуы райком тарафыннан аңа аеруча нык игтибар бирүне таләп итә. Ләкин практикада без аны күрмибез. Мәсәлән, бер ел буена райком работникларыннан безнең оешмада бер кешенең дә булмавы үзе генә дә моны бик ачык күрсәтә.

Кайбер мәсьәләләрне хәл кылганда, аны тиешенчә аңлап җиткермәвебез нәтиҗәсендә, эш процессында җидди кимчелекләр килеп чыга. Мәсәлән, Л. үзен ВКП(б) членлыгына кандидат итеп алуны сорап безнең башлангыч партоешмага гариза биргән иде. Партиянең бөек исемен акларлык булуын эштә күрсәтә алганы юк дип, партҗыелыш аның соравын кире какты. Җыелыш протоколы үз вактында райкомга тапшырылды. Ләкин, райком бу протоколны бөтенләй карамады, игтибарсыз калдырды.

Шуннан озак та үтми, Л. башлангыч оешманың карарыннан риза булмыйча райкомга гариза бирә һәм аның гаризасы бюрода карала. „Башлангыч партоешма Л. нең гаризасына җидди карамаган, Л. партиягә алынырлык һәм тулы хәзерләнгән кеше. Шуңа күрә яңадан карау өчен аның гаризасын башлангыч оешмага кайтарырга“ дигән карар чыгарыла.

Л. нең партиягә алынырлык хәзерлекле булуы, җыелышның аңа җидди карамавы нәрсәдән гыйбарәт? Без аны белмибез. Чөнки Л. турында җыелышта кабул ителгән карарның дөрес булмавын, безнең оешмадагы коммунистларга аңлату өчен райкомнан бер кеше дә килмәде. Башка мәсьәләләрне хәл кылганда да безгә райкомның ярдәме телефон шалтыратудан яки язу җибәрүдән узмый.

Ә. Юсупов.

Партоешма секретаре.

Массовый агитация эшен онытканнар

Әтнә районында кайбер агитколлективлар, хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулардан соң, агитация-масса эшен йомшарттылар. Мисаль өчен Комыргуҗа авылындагы агитколлективны (җитәкчесе иптәш Вафин) алырга мөмкин. Сайлаулар үткәннән соң бу авылда колхозчылар белән бер генә занятие дә үткәрелмәгән. Хәтта агитколлективның сайлаулардан соң эш планы да юк.

Яңа Җөлби һәм Иске Җөлби авылларындагы агитколлективларда да (җитәкчеләре Һадиев һәм Гарифҗанов иптәшләр) шундый ук хәл. Бу агитколлективларның җитәкчеләре эшне нәрсәдән башларга, колхозчыларга нәрсәләр аңлатырга кирәклеген белмиләр. Алар пропаганда работникларының январь аенда булып үткән өлкә киңәшмәсе материалларын өйрәнмәгәннәр.

Калинин районы авыл хуҗалыгы алдынгыларының мөраҗәгате, „Колхозларда бөртекле культуралар чәчүне планлаштыру тәртибе турында“, „Колхозларда бөртекле культураларның сортлы чәчүлекләрен планлаштыру турында“ ВКП(б) Үзәк Комитеты, СССР Совнаркомы карарлары, „1940 нчы елгы язгы чәчүгә хәзерлек турында“ ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитетының VIII нче пленумы карарлары колхозчыларга аңлатылмаган.

С. Мостафин.

Арча райкомының партия кабинетында. РӘСЕМДӘ (алгы планда): комсомолецлардан Г. Ихсанов һәм С. Хабреева иптәшләр „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнү вактында.

А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Сәүдә комиссиясенең башлангыч эше

Хезмәт ияләре депутатларының Казан Шәһәр Советының сәүдә комиссиясе үзенең эшен 25 нче январьда булган беренче утырышында башлап җибәрде. Ул, шәһәр башкарма комитетының сәүдә бүлеге эшенә контрольлек итүне, аның белән нык элемтә тотуны үзенең бурычы итеп куйды. Без район советы сәүдә комиссиясенең, барлык депутатларның һәм совет активының якыннан булышлыгы белән культуралы совет сәүдәсе өчен көрәш оештырырга тиешбез. Шулай ук без спекулянтларга, товар җыючыларга, акча туздыручыларга һәм совет сәүдәсен таркатырга маташучы башка элементларга каршы нык көрәшергә тиешбез.

Сәүдә комиссиясе ярдәме белән милиция органнары түбәндәге фактларны ачтылар: Апас районының Кулит авылыннан килгән Хәбибуллин 40 килограмм, Лаиш районыннан килгән Абрамов 20 килограмм икмәк җыйганнар. 30 нчы январьда Исхаков 40 килограмм икмәк һәм 8 пот бодай белән тотылган. Федосеевский урамында торучы Иванов 52 килограмм икмәк алган. Аның 32 килограммы яшереп куелган урында күгәргән.

Депутатлар һәм совет активы магазиннарга беркетелделәр. Алар сәүдәне дөрес оештыруда һәм спекуляциягә каршы көрәштә милиция органнарына ярдәм күрсәтәләр. Шушы эштә шәһәр советы депутатларыннан Границкая, Нечаев, район советы депутатларыннан Якупова, Щербакова, Заһидуллина, Исхакова һәм башка иптәшләр зур активлык күрсәтәләр.

Сәүдә комиссиясе членнары сәүдә эшләрен оештыру белән берлектә, балалар бакчаларының һәм ясельләрнең кирәк-яраклар белән тәэмин ителүләрен дә тикшерәләр.

Моннан тыш, комиссия членнары аерым поручениеләрне дә үтиләр. Мәсәлән, Чеботарев иптәш ТАССР Сәүдә наркоматын тикшерү буенча Татарстан Совнаркомы янында оештырылган комиссиягә җитәкчелек итә.

Эштәге тәҗрибәләрне уртаклашу һәм һәрбер депутатның эшенә җитәкчелек итү теләге белән, Комиссиянең утырышын кимендә һәр айда ике тапкыр үткәрергә һәм утырышка район сәүдә комиссияләре председательләрен чакырырга булдык.

Сәүдә комиссиясе киләсе утырышта үзенең февраль һәм март айлары планын караячак. Бу план шәһәр башкарма комитетының квартал планыннан чыгып төзелде. Аерым алганда бу планга ТАССР ның XX еллыгына хәзерләнү буенча сәүдә оешмаларында социалистик ярышның торышы, Горпищеторгның сәүдә предприятиеләрендә жалобаларны тикшерүнең торышы, Киров районы Пищеторг базаларында, складларында яшелчә һәм тиз бозылучан продуктларны саклауның торышын карау һәм башка мәсьәләләр кертелде.

Комиссия членнарының барсы да хезмәт ияләренең ышанычларын тулысынча аклау теләге белән сугарылганнар. Безнең комиссия, сайлаучыларның якыннан ярдәм итүләре белән, үз алдына куелган бурычларны намус белән үтәр.

Суганов.

Хезмәт ияләре депутатларының Казан Шәһәр Советының сәүдә комиссиясе председателе.

ЯҢА УҢЫШЛАР ӨЧЕН

Хезмәт ияләре депутатларының Буденный район советына сайланган депутатлар сайлаучылар тарафыннан бирелгән наказларны үтәү өчен, яңа уңышларга ирешү өчен ныклы эшкә керештеләр. Район советы январь аенда авыл хуҗалыгы алдынгыларының киңәшмәсен үткәрде. Киңәшмәдә 1940 нчы елда югары уңыш алу мәсьәләсе тикшерелде. Киңәшмәгә катнашучылар, һава шартларының нинди генә булуына да карамастан, быел гектардан кимендә 100 пот уңыш алу турында конкрет йөкләмәләр алдылар һәм моңа ирешү өчен конкрет чаралар билгеләнде.

„Ирек“ һәм „Искра“ колхозларында югары уңыш өчен көрәш һәм язгы чәчүгә хәзерлек бик начар тора иде. Район советы бу мәсьәләне тикшереп карар кабул итте. Нәтиҗәдә, бу колхозларда хәзер югары уңыш өчен көрәш киң колач алды. Кар тоту яхшы итеп үткәрелде. „Ирек“ колхозында стахановчылар мәктәбе оештырылды, анда занятиеләр системалы үткәрелеп килә. Һәр ике колхозда да агрономия белемен өйрәнү түгәрәкләренең эшләре җанландырылды.

Авыл советларына җитәкчелек чагыштыргысыз яхшырды. Авыл советы председательләренең киңәшмәләре үткәрелеп, ничек эшләү турында аларга конкрет күрсәтмәләр бирелде. Район советы башкарма комитеты членнары авыл советларына чыгып, аларга эш планнарын төзүдә ярдәм иттеләр. Авыл советлары үзләренең эшләрендә шактый борылыш ясадылар инде.

Укый-яза белмәүчелекне бетерү өлкәсендә дә район советы шактый эшләр башкарды. Иске Тинчәле авылында бу эш аеруча начар тора иде. Район советы башкарма комитеты утырышында бу турыда информация тыңлаганнан соң, Иске Тинчәле авылында бу эш юлга салынды. Район советы Татарстанның XX еллык юбилей көненә райондагы барлык колхозчы һәм колхозчы хатын-кызларны рус графикасы нигезендә төзелгән яңа алфавитны нык үзләштерүләренә ирешүне бурыч итеп куйды.

Район Советы 1940 нчы елгы Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә хәзерлек, юл төзелеше, яңа йортлар салу һәм авылларны яшелләндерүгә хәзерлек буенча күп кенә эшләр башкарды. Район үзәгендә артезиан коесы казу башланды. Моңа 52 мең сум акча тотылачак. 1940 нчы елда район үзәгендә культура йорты, магазин салыначак һәм больница өчен 50 мең сумга төшерелеп кухня төзеләчәк. Шулай ук колхозчылар йорты салу эше планга кертелде. Янтуган авылында урта мәктәп, Зур Чынлы авылында яңа клуб салу эшләре башланды һәм Ракова авылында яңа күпер (60 метр озынлыкта) салу эше уңышлы рәвештә дәвам итә.

Буденный район советы һәм барлык депутатлар үз алларында торган бурычларны, һич шиксез, уңышлы үтәячәкләр.

А. Яфизов.

***

Хезмәт ияләре депутатларының Чепья район Советы башкарма комитеты ныклап эшкә кереште. Башкарма комитет утырышлары план буенча 10 көнгә бер тапкыр үткәрелә. 5 нче январьда булган утырышта җирле Советларга сайлауларның йомгаклары, колхозларда доход бүлүнең барышы турындагы мәсьәләләр тикшерелде.

25 нче январьдагы утырышта юл төзү эшләренең барышы турында Иске Чепья авыл советы председателе иптәш Николаевның доклады һәм башка мәсьәләләр тыңланды. Утырышларда кабул ителгән карарларның үтәлеше системалы рәвештә тикшерелеп торыла.

Район Советының башкарма комитеты өч айлык эш планы төзеде. Утырышлар хәзерлек белән үткәрелә, каралачак теге яки бу мәсьәләләр 3—4 көн элек хәзерләнеп куела.

Әле район советы башкарма комитеты эшендә кайбер җитешсезлекләр дә бар. Мәсәлән, авыл советларының һәм район Советының даими комиссияләренең бу көнгә кадәр эшкә керешкәннәре юк. Бу җидди кимчелекне ашыгыч бетерергә кирәк һәм даими комиссия председательләренә һәр яклап ярдәм итәргә кирәк.

Х. Галләмов.

Партия пропагандасына җитәкчелек итәргә

Серго Орджоникидзе исемендәге заводта соңгы вакытларда партия пропагандасының куелышы шактый яхшырды. Коммунистлар, комсомолецлар һәм партиясез интеллигенция большевизм тарихын зур тырышлык белән өйрәнәләр.

Партия оешмалары оператив җитәкчелек итә торган учреждениеләрдә пропаганда үрнәк булырлык итеп оештырылган. Заводның үзәк лабораториясен алыйк. Монда партия оешмасының секретаре иптәш Киязов партия тарихын өйрәнүдә үзе яхшы үрнәкләр күрсәтә. Ул „Кыскача курс“ ның VIII бүлеген өйрәнде инде. Аның җитәкчелегендәге оешманың коммунистлары һәм 15 тән артык партиясез иптәшләр V—VI нчы бүлекләрне өйрәнәләр. Алар ВКП(б) райкомы тарафыннан оештырыла торган лекцияләргә коллектив рәвештә системалы йөриләр.

Иптәш Киязов партия тарихын һәрбер иптәшнең ничек өйрәнүен көндәлек рәвештә күзәтеп бара. Иптәш Киязов IV нче бүлекне өйрәнүдәге үз тәҗрибәләрен коммунистлар белән уртаклашты. Оешмада IV нче бүлек буенча берничә тапкыр теоретик беседалар үткәрелде.

Нәтиҗәдә барлык иптәшләр дә IV нче бүлекне өйрәнүне уңышлы башкардылар.

Иптәш Серединский секретарь булган партоешмада да партия тарихын өйрәнү уңышлы бара. Иптәш Серединский партия тарихының Октябрьдән соңгы чорын өйрәнә, беренче чыганаклардан файдалана. Шуның өстенә ул марксизм-ленинизм буенча кичке университетта укый. Коммунистлар һәм партиясез интеллигентлар өчен теоретик мәсьәләләр турында беседалар үткәрә.

Октябрьдән соңгы чорны үрнәк булырлык итеп өйрәнүче Никулин, Боков, Шабанов, Суханов, Коклянов, Хәмитев, Сушков, Таҗиев, Столбова кебек иптәшләрне күпләп санарга була. Иптәш Столбова „кыскача курс“ ны өйрәнүгә партиясез иптәшләрдән 15 кешене тартты. Ул алар белән һәр вакыт лекцияләргә йөри. Иптәш Столбова җирле Советларга сайлаулар вактында агитатор булып эшләде. Соңгы көннәрдә генә партия оешмасы иптәш Столбованы партия сафларына кабул итте, хәзер ул цехта коммунистлар һәм эшчеләр арасында зур авторитет белән файдалана.

Электросварщик иптәш Коклянов партия тарихын гаять зур кызыксыну белән өйрәнә. Ленин—Сталин хезмәтләрен укый, лекцияләргә регуляр рәвештә йөри. Ул производствода алдынгы стахановчы.

Партия пропагандасына җитәкчелек итмәгән цехларда һәм бүлекләрдә партия тарихын өйрәнү эше начар тора. Электростанциясе янындагы партоешмада учетта торучы коммунистларның күпчелеге „Кыскача курс“ ның II һәм III нче бүлекләрен өйрәнүдән узганнары юк әле. Партоешма секретаре иптәш Антонов үзе дә икенче бүлекне генә өйрәнгән. Хәзер ул партия тарихын өйрәнү эшен бөтенләй туктаткан. Райкомда булган беседа вактында иптәш Антоновның беренче-икенче бүлекләрне дә ныклап өйрәнмәгәнлеге, конспект төземәгәнлеге беленде. Партбюро членнары Устюжанин һәм Спрогец иптәшләр дә партия тарихын өйрәнүдә артта баралар. Оешманың җитәкчеләре партия тарихын өйрәнүчеләр белән беседалар үткәрмиләр, бу эшне үз агымына куйганнар. Райком янында уздырылган беседада станциянең җитәкче работникларыннан 18 кешенең теоретик мәсьәләләр белән бик йомшак шөгыльләнүе беленде. Аларның күбесе „кыскача курс“ ның I-II нче бүлекләрен генә өйрәнгән.

Бу партоешмада гомуми белемнәре аз булган иптәшләр, моннан алты-җиде ай элек үк инде, партия тарихын өйрәнү буенча түгәрәк оештыруны сораганнар иде. Ләкин партия оешмасы шушы көнгә кадәр түгәрәк оештырмаган. Станция начальнигы—ВКП(б) райкомы бюросы члены иптәш Коваленко станциядә партия тарихын өйрәнү эшен яхшыртуда партия оешмасына ярдәм итми.

Заводның хезмәтне оештыру бүлегендә дә шундый ук хәл. Монда да коммунистларның күпчелеге әле беренче-икенче бүлекләрне өйрәнү өстендә генә эшлиләр. Дөрес, кайбер иптәшләр „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ басылып чыгу белән үк инде партия тарихын өйрәнүгә зур дәрт белән керешкәннәр иде. Ләкин партия оешмасының һәм аның секретаре иптәш Сокуновның эшне үз агымына куюлары нәтиҗәсендә, бу инициатива тукталып калган. Иптәш Сокунов үзе дә „Кыскача курс“ның 2 нче бүлеген генә өйрәнә әле. Бүлекнең начальнигы коммунист иптәш Ратченко да шуннан ерак китмәгән.

Цех начальнигы коммунист иптәш Будников партия тарихын „өйрәнү“ дә үзенә бер „метод“ уйлап тапкан. Ул „кыскача курс“ ның 3 бүлеген бер юлы „өйрәнергә“ керешкән. Аның бу „методка“ көчүе көтелмәгәндә генә булмаган, әлбәттә. Бер вакыт аны парткомга беседага чакыралар. Ул башта килмичә йөри, парткомның ике-өч көннән чакыруын үтенә. Ул әле бу вакытта „кыскача курс“ның II нче бүлеген генә өйрәнгән була. 3 көн эчендә ул тагын 3 бүлекне бер юлы өйрәнеп, „5 бүлекне өйрәндем“ дип парткомга „рапорт“ белән килмәкче була.

Иптәш Будников җитәкчелек итә торган цех производство планын үтәүдә цехлар арасында артта сөйрәлеп килә, цехта хезмәт дисциплинасы түбән, массовый-политик эш йомшак. Бу цехның коммунистлары барысы да диярлек „кыскача курс“ның II-III нче бүлекләрен генә өйрәнәләр. Ә партия оешмасы теоретик белемнәрен күтәрү өстендә эшләмәүче коммунистлар тирәсенә җәмәгать фикерен тупламый.

Заводның җитәкче работниклары арасында партия тарихын өйрәнү гаять йомшак тора. Завод директорының урынбасары Липатов, директор ярдәмчесе Мельникова һәм өлкән бухгалтер Греченко иптәшләр дә шушы көнгә кадәр III нче бүлектән узганнары юк. Алар бер вакытта да лекцияләргә йөрмиләр, теоретик беседаларга катнашырга вакыт „таба алмыйлар“.

Бу фактлар барысы да заводта партия пропагандасының үз агымына куелуы турында сөйлиләр. Чөнки завод парткомы, беренче чиратта аның секретарьлары Мальцев һәм Аникин иптәшләр партия пропагандасына җитәкчелек итмиләр, һәр төрле карарлар чыгару белән генә чикләнеп киләләр. Мальцев һәм Аникин иптәшләр партия пропагандасы темасына коммунистлар белән, цех һәм бүлек партоешмаларының җитәкчеләре белән һичбер төрле беседа үткәрмиләр.

Парткомның беренче секретаре иптәш Мальцев партия тарихын өйрәнергә үзе дә вакыт „таба алмый“. Ул да „кыскача курс“ның икенче бүлеген генә өйрәнә.

Завод партоешмасының беренче февральдә булган ачык җыелышы заводта партия пропагандасының куелышында зур җитешсезлекләр барлыкны ачты. Партия пропагандасы өлкәсендә булган җитешсезлекләрне бетерү буенча җыелыш конкрет карар кабул итте. Завод партоешмасы бу карарны үтәү, партия пропагандасын үрнәк булырлык итеп кую өчен барлык чараларны күрергә тиеш.

Г. Миңнул.

ТӘҖРИБӘЛӘРНЕ УРТАКЛАШУ ӨЧЕН

Звено булып эшләүгә күчкәч

Звеноларга бүленеп эшләгәнгә кадәр безнең колхозыбызда эштә иясезлек һәм хезмәт көннәре язуда тигезләүчелек кебек кимчелекләр еш кына була иде. Бу хәл, әлбәттә, авыл хуҗалыгы эшләренең соңга калып һәм начар сыйфат белән үтәлүенә илтә иде. ВКП(б) ның XVIII нче съездыннан соң без звенолап эшләүгә күчтек. Болай эшләү безгә һәр эшне вакытында үтәргә һәм иген уңышын күтәрүгә зур ярдәм итте.

Колхозыбызда үткән елны бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 8 центнер уңыш чыкты. Ә безнең звенобыз үзенә беркетелгән 40 гектар мәйданда уртача 12 центнер уңыш алды.

Безнең звенобыз язгы чәчүгә яхшы хәзерләнә. Кар тоту, көл һәм кош тизәге җыю кебек эшләр буенча бирелгән планны без әллә кайчан үтәдек инде. Звено членнары бөтенесе дә колхозда оештырылган ефремовчылар мәктәбенә йөриләр. Мәктәптә 7 занятие үткәрелде инде.

Без быел бөртекле барлык культуралар буенча үз звенобызда һәр гектардан кимендә 100 пот иген уңышы алуга ирешү өчен көрәшәбез. Ике гектар мәйданда тарының һәр гектарыннан кимендә 200 пот уңыш алырга булдык.

Князева.

Куйбышев районы, „Возрождение" колхозы звеноводы.

Зур күтәренкелек белән

(Телефон буенча)

Чепья районы колхозчылары, колхозчы хатын-кызлары һәм МТС эшчеләре авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсе мөраҗәгатен зур күтәренкелек белән каршы алдылар һәм бу мөраҗәгатне җентекләп өйрәнәләр.

Иске Чепья авыл советы бу мөраҗәгатне өйрәнү буенча киңәшмә үткәрде. Киңәшмәдә катнашучы активистлар, стахановчылар мөраҗәгатне өйрәнгәннән соң быел югары иген уңышы яулап алу буенча конкрет йөкләмәләр алдылар. Алар чәчү орлыкларын тулысынча яхшы кондициядә хәзерләп куюны 1 нче мартка, машиналарга ремонт ясауны һәм минераль ашламалар кайтаруны 15 нче февральгә, кышкы агротехника чаралары планын тулысынча тәгәлләргә сүз биреп, Тельман исемендәге колхозны социалистик ярышка чакырдылар.

Киров исемендәге колхозда стахановчылар киңәшмәсе булды. Киңәшмәдә язгы чәчүгә үрнәк рәвештә хәзерләнү, колхозда бер ефремовчы звено оештыру, кирәкле санда механизатор кадрлар хәзерләү һәм колхоздагы стахановчылар мәктәбендә укучы 48 кешедән тыш бу мәктәпкә яңадан 50 кеше тарту турында карар кабул ителде.

„Правда" колхозының барлык бригадаларында да киңәшмәләр үткәрелеп, авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсе мөраҗәгате өйрәнелде. Һәм мөраҗәгаттә күрсәтелгәннәрне тормышка ашыру буенча конкрет чаралар билгеләнде.

Х. Галләмов.

Биектау районының барлык колхозларында да Татарстан авыл хуҗалыгы алдынгылары киңәшмәсенең мөраҗәгатен тикшерүгә багышланган җыелышлар үткәрелә.

„Красное Ядро" колхозы членнары үзләренең җыелышларында язгы чәчү өчен орлыклар хәзерләүне 20 нче февральгә, авыл хуҗалыгы инвентарьларына ремонт ясауны 25 нче февральгә тәмамларга карар биреп, „Гудок" колхозын социалистик ярышка чакырдылар. Сосновка авыл советының Буденный исемендәге колхозы членнары язгы чәчүгә хәзерлекне 15 нче февральгә төгәлләү турында карар чыгардылар. Колхозчылар быел һәр гектардан кимендә 18 центнер уңыш алуга ирешү турында йөкләмә алдылар. Бу колхоз членнары уңышны күтәрү өстендә тырышып эшләүләре нәтиҗәсендә 1939 нчы елны да һәр хезмәт көненә 5,5 әр килограмм доход бүлделәр.

(ТатТАСС).

ТАГЫН ДА ЯХШЫРАК ЭШЛӘРБЕЗ

Иген уңышын күтәрү, партиябез һәм хөкүмәтебез тарафыннан өзлексез рәвештә кайгыртучанлык күрсәтелү нәтиҗәсендә, колхозчылар культуралы, таза тормышта яшиләр.

Ләкин без хәзергә кадәр ирешелгән уңышлар белән генә һич тә тынычлап кала алмыйбыз. Без социалистик игенчелекне тагын да һәм тагын да югарырак күтәрә барырга, колхоз басуларының уңыш бирүләрен тагын да арттырырга, агрономия фәненнән һәм бай тәҗрибәләрдән максимум файдаланырга тиешбез.

Буа районы, Каганович исемендәге колхоз, барлык агрономия чаралары комплексын дөрес куллану нәтиҗәсендә, ел саен югары иген уңышы алып килә. Без соңгы өч елда бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 91 пот иген уңышы алдык.

Безгә бу уңышны алуга ирешүне нинди чаралар тәэмин итте соң? Барыннан да элек, шуны әйтергә кирәк: агрономия чараларының тулы комплексын үткәрү уңышларга ирешүебездә хәл итkеч шартларның берсе булды. Язгы чәчүне иң кыска срокта һәм югары сыйфат белән үткәрүгә без аеруча нык игтибар биреп киләбез. Без, кагыйдә буларак, һәр елны камылны лущит итәбез, кимендә 20—22 сантиметр тирәнлектә туңга сөрәбез. Барлык уҗым басуында кар тотабыз. Яз көне уҗымнарны тырмалыйбыз. Җирле һәм минераль ашламалардан тулысынча файдаланабыз. Барлык чәчүлекләрдә дә бер генә чүп үләнен дә калдырмый утыйбыз.

Безнең колхоз членнары быел бөртекле культураларның һәр гектарыннан кимендә 100 пот иген уңышы алуга ирешүне йөкләмә итеп алдылар. Моның өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Колхозыбыз язгы чәчүгә һәр яктан хәзер: орлыклар тазартылды, авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясалды, кар тоту планы арттырып үтәлде. (500 гектар урнына 540 гектар). 180 центнер көл җыйдык, башка төрле ашламалар җыю планнарын да тулысынча үтәдек. Барлык бригадаларда да агрономия укулары оештырылды. Бригадаларда даими 12 звено оештырдык. Бригадалар, звенолар һәм колхозчылар арасында социалистик ярыш договорлары төзедек.

Мин Татарстан АССР колхозчыларын һәм барлык колхозчы хатын-кызларын, һава шартларының ничек булуына карамастан, Сталинчыл югары иген уңышы алу өчен, колхоз тормышының яңа җиңүләре өчен көрәшкә чакырам.

Ф. Җәмалиева.

СССР Верховный Советы депутаты, Буа район башкарма комитеты председателенең урынбасары.

Югары иген уңышы алуга мин ничек ирештем

Үткән елны туфракта дым житәрлек булмады. Шулай булуга да карамастан, безнең бригадабыз бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 12,9 центнер иген уңышы алды. Гектарыннан 24 центнер уңыш биргән участкыларыбыз да булды. Мәсәлән, 82 гектар мәйданда арышның һәр гектарыннан уртача 22 центнер, ә аерым участкыларда 24 центнер уңыш чыкты. Уҗым бодае да бик яхшы уңды: 8 гектар мәйданда һәр гектардан уртача 22 центнер уңыш җыеп алдык.

Бу уңышны алу өчен без үзебезнең бригадабызда түбәндәге төп чараларны үткәрдек: парны май аенда ук һәм тирән итеп сөрдек. 4—5 сантиметр тирәнлектә ике тапкыр культивацияләдек һәм бик яхшылап тырмаладык. Чәчү алдыннан 12 гектар мәйданга, һәр гектарга 25 тонна хисабыннан, бик яхшы хәзерләнгән тирес керттек. Көз көне чүп үләннәрен бер дә калдырмый утадык һәм кыш көне кар тоттык. Язга чыкканнан соң уҗымнарны фекаль белән тукландырдык һәм шуннан соң буразнага аркылы итеп тырмаладык. Уҗым бодаена карата да шундый ук чараларны үткәрдек.

Без хәзер агрономия чараларын дөрес үткәргәндә нинди генә начар һава шартларында да югары иген уңышы алырга мөмкин икәнлегенә нык ышандык. Шуңа күрә без йөзпотчылар хәрәкәтенә зур теләк белән һәм җиңүебезгә тәмам ышанган хәлдә кушылдык. Язгы чәчүгә нык хәзерлек алып барабыз. Барлык инвентарьга ремонт ясауны 1 нче январьга кадәр үк тәмам иттек. Җирле ашламалардан тирес, көл, кош тизәге һәм фекаль кебек ашламаларны җыеп барабыз һәм басуга чыгарабыз.

Безнең колхоз членнарының 50 проценты татарлар, 50 процентка якыны руслардан тора. Чуваш һәм чирмешләр дә бар. Безнең колхозда эшләү аеруча күңелле. Барыбыз да бердәм булып эшлибез. Бер-беребезне ихтирам итәбез. Милләтләр арасында шундый нык дуслык тудырган өчен, безгә якты тормыш биргән өчен бөек партиябезгә, остазыбыз иптәш Сталинга без һәр вакыт рәхмәт әйтәбез.

Челяков.

Юдино районы, „Яңа тормыш" колхозы.

Лаиш районының „Путь Ленина" һәм „Победитель" колхозлары үзара ярышып эшлиләр. РӘСЕМДӘ: „Победитель" колхозының тикшерү комиссиясе члены иптәш П. С. Котлов (сулда) бригадир иптәш М. А. Зеленинга ремонтның җитешсез ягын күрсәтә.

С. Чиколкин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Социалистик ярыш нәтиҗәсе

Бөек илебезнең һәр тармак буенча—промышленность буенча да, авыл хуҗалыгы буенча да зур уңышларга ирешүендә социалистик ярышның әһәмияте һәрберебезгә ачык билгеле. Колхозларны оешу-хуҗалык ягыннан ныгытуда, аларны большевистик колхозларга, ә колхозчыларны таза тормышлы кешеләргә әйләндерүдә социалистик ярышның роле безгә ачык билгеле.



Социалистик ярышны киң җәелдерү нәтиҗәсендә безнең Чувашстан АССР колхозлары соңгы елларда гаять зур уңышларга ирештеләр. Без 1939 нчы елда бөртекле барлык культуралар буенча гектарыннан уртача 8,3 центнер уңыш алдык. Республикабызда 1.690 колхоздан 23 колхоз үткән елны бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 100 пот иген уңышы алды. Республикабызның иң алдынгы колхозларыннан „Динамо" колхозы үткән елны 600 гектар мәйданда һәр гектардан 19,25 центнер уңыш җыйды.

Бу уңышлар барлыгы да агрономия чаралары комплексын тулысынча үтәү өчен социалистик ярышны киң җәелдерүнең нәтиҗәсе булып торалар. Без үз республикабыздагы уңышлы тәҗрибәләрне башка республика колхозларына күчерергә һәр вакыт хәзер торабыз.

Серебренников.

ВКП (б) ның Чувашстан Өлкә Комитетының авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире.

Бригадир

Актаныш МТС ы үткән елны да беренчелекне бирмәде. Татарстан Машина-трактор станцияләре ярышында ул иң алдынгы, иң мактаулы МТС булып чыкты.

Без аның гүзәл эше, аның алдынгы бригадирлары, алдынгы тракторчылары белән яхшы таныш. 1938 нче елда МТС та беренчелекне алган бригадир Гобәйдулла Ганиев иптәшне, алдынгы бригадирлардан орденлы Гыйлми Хафизов, Әбүзәр Фатыйхов һәм Моталлип Фәрхетдинев иптәшләрне без күреп тә, газеталарда чыккан мәкаләләр буенча да беләбез.

Ләкин авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсенә быел Ганиев тә һәм Хафизов та килмәде. Ә иң алдынгы бригадир булып чыккан Әһли иптәш Агләмов килде.

Киңәшмә барган көннәр. Без—ике тракторчы, бер комбайнчы һәм мин—Агләмов иптәш белән танышырга теләп, менә инде икенче тапкыр, гостиницаның паласлы озын коридоры буйлап барабыз.

Менә Актаныш МТС ы делегатлары урнашкан бүлмә. Шакылдатабыз. Керәбез.

Җыйнак, матур итеп җыештырылган бүлмә. Никелле кроватьлар, яхшы, мәһабәт мебельләр, авыр шторлар.

Безне тәбәнәк буйлы, саргылт чәчле бер егет каршы ала.

— Гафу итегез,—дим мин,—безгә Агләмов иптәш кирәк иде.

Саргылт чәчле егетнең күзләре чаткыланып китә:

— Агләмовмы сезгә? Рәхим итеп танышыгыз. Мин булам ул.

Аның гадилеге, ачык йөзлелеге, эчкерсезлеге безне бик тиз якынлаштырды. Аның белән без бик тиз дуслашып китеп, сөйләшеп утыра башладык.

Бераздан соң без аңа:

— Синең бригада ничек итеп беренчелекне алды? Сөйләп бир. Тәҗрибәң белән уртаклаш,—дидек.

Егет сүзгә саран булып чыкты.

— Бригададагы иптәшләр яхшы иде минем, бик бердәм иделәр. Барыбыз да социалистик ярышка катнаштык. Машиналарга техник уходны вактында, инструкциядә күрсәтелгәнчә үткәрдек. Менә шул. Башка әйтерлек сүз юк,—диде ул.

Юк, бу җавап безне канәгатьләндерми иде. Без тулырак, ачыграк сөйләвен үтендек.

Ахырда ул гади генә, буяусыз гына, мактанмый гына сөйләп бирде. Без ялгышканбыз. Егетебез сүзгә һич тә саран түгел икән!

... 1936—38 нче елларда ул бригадир ярдәмчесе булып эшли: ике ел Ганиев бригадасында, бер ел орденлы Гаяз Вәлиев бригадасында. Ул аларның тәҗрибәләрен, эш методларын үзләштерә, өйрәнә.

Ул начар эшче булып түгел, ә яхшы эшче булып санала. Ләкин, 1938 нче елда аны күрми калалар: ул Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә кандидат итеп билгеләнми. МТС тан барлыгы 60—70 кеше билгеләнә, ләкин алар арасында Агләмов иптәш исме булмый. Бу нәрсә аның йөрәген өзеп ала. Ул борчыла: „Ни өчен мин кандидат була алмадым—ди.

Аны тынычландырмакчы булалар. Очраклы хаталар турында мисальләр китерәләр. Ләкин Агләмов күңеле аның белән генә тынычланмый. Ул МТС та беренчелекне алырга үз-үзенә бик нык сүз бирә. Һәм моңа хәзерләнә, китаплар укый, алдынгы бригадирларның, тракторчыларның киңәшләрен тыңлый, бик җентекләп өйрәнә.

1939 нчы елда ул, батырланып, үзенә бригада сорый. Бирәләр. Кешеләр комплектовать ителеп беткәч тә ул, башка бригадаларга караганда, колхозларга бер унбиш көн элегрәк чыга. Анда ул прицепщиклар, керосин, су ташучылар һәм аш пешерүчеләрне билгеләтә. Алар белән бик ныклап таныша. Кайберләрен кабул итми,—икенчеләрне билгеләтә. Басуларны карап чыга, маршрутлар төзи. Колхоз бригадалары белән трактор бригадалары арасында эшне бергә бәйләп алып бару турында бригадирлар белән киңәшә. Бригада членнары белән эшкә хәзерләнә: укыйлар, өйрәнәләр, план төзиләр.

Социалистик ярышка алар Хөҗҗәт Вәлиев бригадасын чакыралар. СТЗ тракторына 1.000 гектар эшләргә йөкләмә алалар. Бригада членнары үзара да ярыш ачалар.

Менә шунда инде ул үзенең серен иптәшләренә сөйләп бирә.

— Без Хөҗҗәт бригадасын гына түгел, ә Ганиев һәм Хафизов бригадаларын да узарга тиеш,—ди.

— Без кемнән ким! — диләр бригада членнары. Һәм, иглан итмичә генә, МТС тагы иң алдынгы бригада белән ярышалар.

Менә беренче сводкалар килә башлый. Ләкин Агләмов бригадасы әле беренче урында түгел. Хөҗҗәт бригадасы да аны шактый калдырып бара. Агләмов бөтен көчен куя, тракторның һәр минутыннан файдалана. Ләкин, бәхетсезлеккә каршы, нак шул көннәрдә, аның бер тракторы ватыла. Агләмов аны үз көче белән генә төзәтә алмый, мастерскойга йөгерә. Берничә көн үтә. Ә ул арада бригада бишенче, алтынчы урынга кала, хәтта җиденче урынга кадәр барып җитә.

Менә шунда ул, мастерскойда, әрнеп, борчылып, үз серен, югалып барган хыялын механик Әлмөхәмәтовка сөйләп бирә. Әлмөхәмәтов аның күңлен күтәрергә, дәртләндерергә тырыша:

— Эш узмаган әле. Тырышсаң, Хөҗҗәт бригадасын да, хәтта Ганиев бригадасын да узарга мөмкин,—ди.

Трактор яңадан ходка китә. Ләкин бу ремонт аркасында Агләмов бригадасы тәмам көлкегә кала. Нииндидер бер шаяны:

— Агләмов тракторы карбюраторына йон кергән икән дә, ул шуны чыгара алмыйча бер атна йөргән, — диган хәбәр таратып өлгерә.

Кайберәүләр, бу хәбәргә ышанып, чынлап көлә башлыйлар.

Агләмов ни эшлисен белми. Бригада членнарын җыя:

— Ишетәсезме, безнең хакта ни тарата лар,—ди.—Кайда безнең вагдәбез? Кайда безнең сүзебез? Картлар: егет сүзе бер булыр, дигәннәр. Егетме без, түгелме?—ди.

Менә яңа сводкалар килә. Һәр сводкада Агләмов бригадасы югарыга үрмәли. Ахырда алар Хөҗҗәт Вәлиев бригадасын артта калдыралар.

Тик шуннан соң гына инде ул, Ганиевне очратып:

— Беренчелекне болай гына бирәсеңме, әллә көрәшеп алыйммы?—ди.

— Егет булсаң көрәшеп ал,—ди Ганиев.

— Алай булса, көрәшеп алам.

— Чынлап әйтәсеңме син, әллә болай гынамы?

— Билгеле, чынлап әйтәм,—ди Агләмов.

Күп тә үтми, Агләмов бригадасы Ганиев бригадасын да һәм Хафизов бригадасын да узып китә. Аннары ул сезон буенча беренчелекне бирәүгә дә бирми.

Нәтиҗәдә, Агләмов бригадасы, көпчәкле һәр тракторга 1.390 гектар эшләп, беренче урынны, ә Гыйлми Хафизов бригадасы, 1.150 гектар эшләп, икенче урынны ала. Ганиев бригадасы исә, өченче урынга кала.

Сезонга йомгак ясаган көнне Ганиев аның кулын каты итеп кыса:

— Молодец, Әһли, кечкенә булсаң да, төш кенә икәнсең!—ди. Һәм шунда ук өстәп куя:—Киләсе елда да әле без синең белән ярышырбыз, белеп тор,—ди.

Агләмов иптәш боларны безгә гади генә, буяусыз-нисез генә сөйләп бирә. Ул сүз уңае туры килгән саен иптәшләрен: Рамазан Гәрәевне, Нургали Фәсхиевне, Хәйрулла Хәбибуллинне һәм башкаларны мактап искә ала.

— Бригадамдагы егетләр бик яхшы иде минем,—ди ул.

— Ә киләсе сезонда ничек уйлыйсың?

— Киләсе сезондамы? Киләсе сезонда мин шулай ук беренчелекне бирмәскә тырышачакмын.

Иптәшкә без чын күңелдән уңыш телибез, кулын кысабыз. Шулай ук без Ганиев һәм Хафизов иптәшләргә дә киләчәк сезонда зур уңышлар телибез. Һәм бу өч бригадирның бик нык ярышачакларына ышанабыз.

Афзал Шамов.

КАДРЛАР УҢЫШНЫ ХӘЛ ИТТЕЛӘР

Безнең Актаныш МТС ы соңгы өч елда машиналардан файдалану буенча да һәм шулай ук МТС хезмәт күрсәтә торган колхозларда иген уңышын күтәрү буенча да бик яхшы уңышларга иреште. Өч ел рәттән без тракторлар эше планнарын арттырып үтәдек. Шул өч елда йомшак җир сөрүгә күчереп исәпләгәндә 15 ат көчле һәрбер трактор белән уртача 1.323 гектар эшләдек. Барлык колхозларыбызда бөртекле культуралар буенча иген уңышы гектарыннан уртача 11,12 центнер чыкты.

Безгә бу уңышларга ирешүне, барыннан да элек, кадрлар, аларның МТС та күп еллар буенча даими эшләүләре тәэмин итте.

Бездә кадрлар өчен һәр яктан уңайлы эш һәм тормыш шартлары тудырылган. Без моңа аеруча нык игтибар бирәбез һәм бирәчәкбез.

Актаныш МТС коллективы йомшак җир сөрүгә күчереп исәпләгәндә быел 15 ат көчле һәрбер трактор белән уртача 1.500 гектар эшләргә, 15 футлы һәрбер комбаен белән кимендә 500 гектар урып-җыярга һәм МТС хезмәт күрсәтә торган колхозларның бөтенесендә дә бөртекле барлык культуралар буенча кимендә 100 пот иген уңышы алуга ирешүне йөкләмә итеп алды. Без бу йөкләмәне һич шиксез үтәрбез. Хәзер без язгы чәчүгә ныклап хәзерләнәбез. Тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауны төгәлләдек инде.

Садриев.

Актаныш МТС директоры.

ДАНЛЫКЛЫ ЮБИЛЕЙГӘ КАДӘР УКЫЙ-ЯЗА БЕЛМӘҮЧЕЛЕКНЕ БЕТЕРИК

Орденлы Татарстан республикасының данлыклы XX еллыгы якынлаша. Бу көн республикабызның тарихына бөек тантана булып керәчәк. Менә шуның өчен дә хезмәт ияләре республикабызның XX еллыгын гүзәл уңышлар белән каршылау өчен үз өсләренә конкрет йөкләмәләр алдылар һәм аларны тулысынча үтәү өчен сугышчан көрәш башладылар.

Юбилейгә хәзерлек көннәрендә укый-яза белмәүчелекне тәмам бетерү, рус графикасы нигезендәге яңа алфавитны тулысынча үзләштерү—алда торган гаять зур бурычларның берсе. Бүген без шушы турыда редакциягә килгән кайбер хәбәрләрне урнаштырабыз.

Заинский районында

Орденлы республикабызның данлыклы XX еллыгын укый-яза белмәүчелекне тәмам бетерү белән каршы алу—алда торган бурычларның берсе. Бу бурычны тулысынча үтәү өчен Заинский районының күп кенә авылларында шактый эш җәелдерелде. Сарсаз, Баграж һәм башка авылларда укый-яза белмәүчеләр укуга тулысынча тартылганнар. Югары Пәнәче авылында укый-яза белмәүчеләрдән 61 кеше, аз белүчеләрдән 49 кеше һәм допризывниклардан 5 кеше үзләренең белемнәрен күтәрү өстендә тырышып эшлиләр.

„Байрак" колхозында укытучы иптәш Каюмова шушы арада 35 кешене укытып чыгарды. „Кызыл Октябрь" колхозындагы укытучылардан Әхмәтҗанов, Сафина, Матвеева иптәшләр 36 кеше укытып чыгардылар.

Шулай да, районның кайбер авылларында зурларны укыту эше тиешенчә оештырылмаган. Поповка, Липатовка, Дүрт Монча, Федоровка авылларында бу эш аеруча начар оештырылган. Кайбер авылларда укый-яза белмәүчеләрнең дөрес учеты да юк. Район буенча укый-яза белмәүчеләр—1.859, аз укый-яза белүчеләр—1.397 кеше хисаплана. Ләкин аларның күпчелеге укуга тартылмаган.

Район мәгариф бүлеге укый-яза белмәүчелекне бетерү эшенә конкрет җитәкчелек булдырганы юк әле. Нәтиҗәдә, шушындый хурлыклы фактлар бу көнгә кадәр яшәп килиләр. **Л. Максимов.**

Биләр районында

Культура көчләре зур булган Кульбай-Мораса авылында укый-яза белмәүчелекне бетерү эшенең торышы начар. Авылда 47 кеше укый-яза белмәүче һәм 116 кеше аз укый-яза белүче бар. Шуңа карамастан, аларны укыту эше кирәгенчә оештырылмаган.

Рус графикасы нигезендә төзелгән яңа алфавитны өйрәнү эше дә бу авылда начар тора. Үткән елның октябрь аенда авыл активы өчен яңа алфавитны өйрәнү түгәрәге оештырылган иде. 2 занятие үткәрелгәннән соң түгәрәкнең эше ни өчендер туктатылды. Колхозчылар арасында яңа алфавитны өйрәнү эше бөтенләй оештырылмаган.

Авыл оешмалары, хәтта, урта мәктәп җитәкчеләре дә 1940 нчы елның 1 нче январеннан эш башкаруны рус графикасы нигезендә яңа алфавитка күчерү турында ТАССР Верховный Советы Президиумы указын тупас рәвештә бозалар. Алар үзләренең эшләрен иске алфавитта алып баралар.

Биләр районы мәгариф бүлеге һәм аның мөдире иптәш Смирнов укый-яза белмәүчелекне бетерү эшендә авыл оешмаларына конкрет булышлык күрсәтү урнына, телефон аша „сводка" җыю белән генә чикләнә. РОНО мөдиренең урынбасары иптәш Миңлебаев Кульбай-Мораса авылында соңгы вакытта 3—4 тапкыр булган. Ләкин бу мәсьәләнең торышы белән кызыксынырга вакыт таба алмаган.

Авылда һәм район күләмендә укый-яза белмәүчелекне тәмам бетерү иң зур бурычлардан берсе. Моны тиз арада һәм тулысынча үтәүдә кискен борылыш ясалырга тиеш. **Ф. Кыям.**

Татнаркомпроста

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1939 нчы елның май аенда чыгарылган указында: „Эш башкаруны рус һәм татар телендә алып бара торган барлык дәүләт учреждениеләрендә, предприятиеләрдә һәм җәмагат оешмаларында татар телендә эш башкаруны рус графикасы нигезендәге яңа алфавитка 1940 нчы елның 1 нче январеннан күчерергә" диелгән иде. Ләкин Татнаркомпрос бу указны үтәп җиткергәне юк әле.

Биредә рус графикасы нигезендәге яңа алфавитта язу машинасы да 17 нче январьда гына булдырылган. Татар телендә алып барыла торган эш кәгазьләре моңарчы яңалифтә алып барылганнар. Наркомпросның мәктәпләр һәм мәктәпкә кадәр тәрбия бүлекләренең сотрудниклары тарафыннан эш кәгазьләре рус графикасы нигезендәге яңа алфавитта язылсалар да, бастыру өчен язу машинасы булмаганлыктан, алар яңалифтә җибәрелгәннәр. Шуның белән бергә, район мәгариф бүлекләреннән, мәктәп директорларыннан һәм укытучылардан килгән татарча язылган эш кәгазьләренә еш кына русча җаваплар да язылган. Моны Нарком Контюков һәм Лаврова иптәшләр исменнән Кузнечиха районындагы урта мәктәп директорына һәм Әлмәт районы ТБУМ укытучысына 15 нче январьда гына русча җибәрелгән җаваплар ачык күрсәтәләр.

Татнаркомпросның хезмәткәрләре һәм техник работниклары өчен татар әдәби теленең алфавитын һәм орфографиясен өйрәнү түгәрәге бүгенгә кадәр оештырылмаган.

Татнаркомпрос, татар язуын латин алфавитыннан рус графикасы нигезендәге алфавитка күчерү турында Татарстан Верховный Советы Президиумының указын үтәүдә кискен борылыш ясарга тиеш. **М. Закирова.**

Мехкомбинатта

Мех промышленносте эшчеләре профсоюзының район комитеты мехкомбинатының 1, 2, 4 нче фабрикаларында һәм ФЗУ мәктәбендә рус графикасы нигезендәге яңа алфавитны өйрәнү курслары оештырды. Курста; зурлар мәктәбендә укучылардан 651 кеше яңа алфавитны өйрәнә. 46 кеше яңа алфавитны өйрәнү курсын тәмамлап чыкты инде. Соңгы вакытларда стахановчылар мәктәпләрендә дә яңа алфавитны өйрәнү башланды. **Хуҗашев.**

Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгы алдыннан

МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ ЕЛЛЫГЫНА ХӘЗЕРЛӘНӘЛӘР

Васильеводагы (Юдино районы) урта мәктәп укучылары Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының 22 еллыгына актив хәзерләнәләр. Укучылар мәктәпнең яхшы җиһазландырылган хәрби кабинетында противогазны, винтовканы, пулеметны өйрәнәләр. Төз ату эшен үзләштерәләр, оборона темаларына докладлар тыңлыйлар. Укучылардан 83 кеше „ПВХО" значогына норма тапшыралар инде. Укучылардан Мухин һәм Архипова йорт хозяйкаларыннан 25 кешене „ПВХО" значкисты итеп хәзерлиләр.

Югары классларда укучылар шушы көннәрдә 25 километрга хәрбиләштерелгән поход үткәрделәр. Аның 10 километры противогаз киеп үтелде.

Юдинодагы ФЗУ мәктәбендә дә Кызыл Армия көненә хәзерлек киң җәелдерелде. Биредә физкультура һәм Осоавиахим оешмалары, шулай ук РОКК түгәрәге төзелде. Кызыл Армия көненә 332 кеше „Ворошиловча атучы", „ПВХО" һәм „ГСО" значкистлары итеп, 23 кеше пулеметчы итеп хәзерләнәчәк. (ТатТАСС).

БӘЙРӘМНЕ ЗНАЧКИСТЛАР САНЫН АРТТЫРУ БЕЛӘН КАРШЫЛЫЙЛАР

Эшче-Крестьян Кызыл Армиясе һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгын каршылау уңае белән мехкомбинатта оборона значокларына нормалар тапшыру эше сизелерлек рәвештә яхшырды. Хәзерге вакытта комбинат күләмендә Ворошиловча атучы 85 значкист бар. Бөек юбилей көненә тагын 40 кеше „Ворошиловча атучы" значогына нормалар тапшырырга керешге. 23 нче февраль көнне допризывникларның фабрикалар ара ату спорты ярышы үткәреләчәк.

ГТО значогына нормалар тапшыру эше дә уңышлы бара. Комбинат күләмендә 209 ГТО значкисты бар. Данлыклы юбилей уңае белән 2 нче һәм 8 нче февраль көннәрендә массовый төстә ГТО значогына чаңгы буенча норма тапшыру үткәреләчәк. 21 нче февраль көнне Шелангага чаңгы походы оештырыла. **К. Хөсни.**

Шушы көннәрдә Мәчкәрә авылында (Кукмара районы) 1920—21 нче елны туган допризывниклар сборы башланды. Допризывниклар сборда винтовканы, гранатаны, противогазны һәм пулеметны өйрәнәләр. Шулай ук оборона значокларына нормалар тапшыралар.

Осоавиахимның башлангыч оешмасында 83 член бар. Допризывниклар Осоавиахим тарафыннан оештырылган ГТО, ПВХО, ГСО һәм Ворошиловча атучылар түгәрәкләрендә актив катнашалар. **Г. Сибгатуллин.**



Караб рейддә (Кара диңгез флоты). П. Савченко фотосы. (ТАСС фото-клишесе).

ОСОАВИАХИМ ОЕШМАЛАРЫНДА

Татарстанның Осоавиахим оешмаларында Эшче - Крестьян Кызыл Армиясенең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгына хәзерлек башланды.

Н частенең (Киев шәһәренең Аерым Хәрби округы) сугышчан һәм политик отличникларыннан В. А. Игнатович (сулда) һәм П. В. Конишев иптәшләр стереструбалар янында.

Е. Копыт фотосы (ТАСС фотоклишесе).

Казанда һәм районнарда Осоавиахимның башлангыч оешмаларында халыкара хәл һәм СССР ның эчке хәле турында, ак финнәргә каршы Кызыл Армиянең героик көрәше турында һәм башка темаларда лекцияләр, докладлар һәм беседалар үткәрелә. Күп кенә оешмалар янында призывниклардан оборона значкистлары хәзерләү түгәрәкләре төзелде.

18 нче февральдән 24 нче февральгә кадәр колхоз клубларында, культура йортларында һәм кызыл почмакларда данлыклы бәйрәмгә багышланган кичәләр үткәреләчәк. Казанның тулы һәм тулы булмаган урта мәктәпләрендә укучылар арасында ату спорты ярышлары башланды. 24 нче февральдә Казанның Культура һәм Ял паркында оборона бәйрәме үткәрелә. Анда чаңгы буенча ГТО значогына нормалар тапшыру, призывникларның чаңгы ярышлары, граната ыргыту, үз-үзеңне саклау группаларының эшләренә смотр һәм кавалеристларның чыгышлары булачак.

Бәйрәм уңае белән шәһәрдә район командалары арасында ПВХО буенча ярышлар үткәрергә билгеләнде.

Хоккей кубогы өчен

СССР ның хоккей кубогы өчен ярышлар дәвам итә. 6 нчы февральдә СССР ның күп кенә шәһәрләрендә чираттагы очрашулар булды.

Казанның „Спартак" командасы Казанның „Динамо" сын һәм Ижевскийның „Зенит" командасын отып, 16 нчы зонада җиңүче булып чыккан иде. Өченче көн спартакчылар Москваның яхшы командаларыннан „Торпедо" командасы белән очраштылар. Уенда „Торпедо" ның чагыштырмаслык дәрәҗәдә өстен булуы күренде. Москвалылар конькида бик җитез йөриләр, хоккей тубын зур осталык белән йөртәләр, матур комбинацияләр ясыйлар. Казанлыларда бу сыйфатларның берсе дә күренмәде. Аерым уенчылардан Власов һәм Борисевич иптәшләр конькида оста йөрсәләр дә, аларның уен техникасы москвалыларныкына караганда бик күп түбән булып чыкты. Нәтиҗәдә, „Торпедо" командасы уенны бик җиңел алып барды һәм 12:0 исәбе белән отты. **Х.**

ШАШКА ЧЕМПИОНАТЫ

5 нче февральдә шашка буенча Казан беренчелеге өчен традицион турнир башланды. Турнирда 1 нче категорияле көчле шашкачылардан Нәҗметтинев, Алакшин һәм Елисеев, яш шашкачылардан Грудцин, Романов, Трофимов, Сизов һ. б. иптәшләр (барлыгы 12 кеше) шәһәр чемпионы дигән исемне алу өчен көрәшәләр. Беренче тур ук катнашучыларның кискен көрәш алып баруларын күрсәтте. 2 партиядән кала барлык партияләр ничья белән тәмам булды. Романов Нәҗметтиновка, Сизов Трофимовка оттырдылар. 2 партия уйналмады.

Чемпионат Матбугат йортында шахмат-шашка клубында дәвам итә. Икенче тур—9 нчы февральдә булачак.

ӘДӘБИЯТ ТҮГӘРӘГЕ

Зеленодольский шәһәрендә матур әдәбиятны өйрәнү һәм башлап язучыларның әдәби квалификацияләрен үстерүгә ярдәм итү теләге белән, тел-әдәбият түгәрәге төзелгән иде. Бу түгәрәктә хәзер 15 иптәш член булып тора. Алар әдәбиятны җентекләп өйрәнәләр, үзләре язган әсәрләрне укып тикшерү эшләрен алып баралар. Түгәрәккә язучы Идрис иптәш Туктаров җитәкчелек итә. Үзенең эш дәверендә түгәрәк унннан артык әдәби кичә үткәрде. Халык иҗадын өйрәнү, халык шагыйре Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗад юллары белән танышу шикелле мөһим эшләр үткәрелде.

Җирле Советларга сайлаулар уңае белән түгәрәк членнары күп кенә эшләр башкардылар, район газетасының битләрендә үзләренең әдәби әсәрләре белән катнаштылар. **Г. Җэон.**

УМАРТАЧЫЛЫКТАН МУЛ ДОХОД

Теләче районында соңгы елларда умартачылык шактый дәрәҗәдә үсте. Хәзер районның 61 колхозында умартачылык фермалары бар. „Красный Октябрь" колхозы 1939 нчы елда умартачылыктан 50 мең сум доход алды. Бу колхоз 1940 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашу өчен кандидат итеп расланды. Шулай ук, умартачылык эшен яхшы куйган „Красное поле" һәм „Искра" колхозлары да күргәзмәгә кандидат итеп расландылар. **Х. Әхмәтҗанов.**

ЕФРЕМОВЧЫ ЗВЕНОЛАР

Сарман районының 24 колхозында ефремовчы звенолар төзелеп, эшкә башладылар. Бу эшне оештыру буенча колхозларда югары квалификацияле 16 агроном эшли. „Кызыл партизан", „Корыч куя", „Политотдел", „Җиңүче", „Марс" һәм „Кызыл байрак" колхозларында оештырылган ефремовчы звенолар аеруча яхшы эшлиләр.

КИНО ЖУРНАЛНЫҢ ЧИРАТТАГЫ НОМЕРЫ

Союзкинохроникаңың Казан студиясе өч республика киножурналының чираттагы номерын экранга чыгарды.

Журналның бу номерында „Казанда Ленин көннәре", „Ленин музее йорты", 30 нчы номерлы мәктәптә (Удмуртия АССР) пионерларның Ильичка багышланган сборында карт большевик Хмурович белән Ленин турында беседа ясау вакты урнаштырылган. Болар өстенә Йошкар-Олада авыл хуҗалыгы алдынгылары слеты, Казан Медицина институтының 125 еллыгы уңае белән институтның иң карт профессоры—фәннең атказанган эшлеклесе Александр Николаевич Миславский һәм башка кадрлар урнашкан.

Журнал режессер иптәш Аристов җитәкчелегендә, операторлардан Матков, Әмиров һәм Барбутли иптәшләр тарафыннан төшерелгән.

ПИОНЕР ЛАГЕРЛАРЫН ОЕШТЫРУГА ХӘЗЕРЛЕК

Балтач районында пионер лагерларын оештыруга хәзерлек эшләре башланды. Район күләмендә 11 кешедән комиссия төзелде.

Быел районда 300 балалык пионер лагерлары оештырылачак. 100 баланы эченә алган лагер район күләмендә эшләячәк. Пионерларның район лагерын оештыру өчен 19.500 сум акча җибәрелде. Инде лагерның начальнигы һәм җаваплы вожатые билгеләнде.

„Яңа тормыш", „Кызыл яшләр", „Комсомол", „Кызыл Татарстан", „Кызыл үрнәк", „Кызыл чишмә" колхозларында 30 ар балалык лагерлар эшләячәк.

ГТО ның яңа комплексы

ГТО ның яңа комплексы—Советлар Союзының физкультура хәрәкәтендә тарихи документ. Ул—совет физкультурасы системасының нигезе.

ГТО ның яңа комплексы турында СССР Совнаркомы карары социалистик Ватанның ялкынлы патриотларын һәр яктан чыныктырып үстерү турында партиянең һәм хөкүмәтнең кайгыртучанлыгын тагын бер тапкыр күрсәтә.

СССР да физкультура хәрәкәте үзенең бөтен үсеш этапларында социалистик төзелеш бурычларына буйсындырылды.

1920 нче елны ук комсомолның III нче съездында физкультура хәрәкәтенең максатлары билгеләнгән иде. Алар: яшьләрне хезмәткә һәм социалистик Ватанны корал белән саклауга хәзерләү. Ә 1931 нче елда Ленин—Сталин комсомолының инициативасы белән физкультура эше практикасына „ГТО" („Хезмәткә һәм оборонага хәзер") комплексы кертелде. Бу комплекс хезмәт ияләрен хезмәткә һәм оборонага хәзерләүдә әһәмиятле чара булып хезмәт итте. Миллионнарча кешеләр спорт һәм физкультура занятиеләрендә катнаштылар, 5 миллионнан артык кеше ГТО значогының беренче баскычына нормалар тапшырды, 100 меңнән артык кешедә II нче дәрәҗә ГТО значогының II нче баскычы бар һәм 1,5 миллион яшь үсмер горурлык белән күкрәкләрендә БГТО значогын йөртәләр.

Миллионнарча кешеләр катнашкан физкультура хәрәкәте аркасында, талантлы бик күп спортсменнарны, рекордсменнарны һәм Советлар Союзы мастерларын үстерергә мөмкин булды.

Бездә Советлар Союзының иң яхшы вәкилләре—атказанган 122 мастер, рекордсмен бар. Аларның турыдан-туры катнашлары һәм булышлыклары белән 1939 нчы елда гына да Бөтенсоюз күләмендә 128 рекорд куелды, шуларның 17 се бөтен дөнья күләмендәге рекордлар.

Физкультура хәрәкәтендәге моңдый гаять зур колач һәм спорт техникасын үзләштерүдәге зур уңыш бары тик безнең илдә генә—кеше турында Сталинчыл кайгыртучанлык тормышка ашырыла торган илдә генә мөмкин.

Ләкин ГТО ның иске комплексы тәэмин иткән шактый зур казанышлар белән бер рәттән, ул комплексның төзелешендә һәм эчтәлегендә зур гына җитешсезлекләр бар иде. Шулай ук хәзерге вакытта социалистик хезмәтнең яңа формалары, Кызыл Армия сугышчыларын хәзерләүдәге күтәренке таләпләр физкультура хәрәкәте алдына физик тәрбия системасын яхшырту бурычын куйдылар. Физкультура хәрәкәте хезмәт ияләрен хезмәтнең югары җитештерүчәнлегенә һәм СССР оборонасына хәзерләү бурычларын тизрәк үтәүне тәэмин итәргә тиеш.

ГТО комплексы проекты масса арасында озак тикшерелде һәм фәнни яктан җентекләп эшләнде. СССР Совнаркомы 1939 нчы елның 26 нчы ноябрендә чыгарган карары белән 1940 нчы елның 1 нче январеннан ГТО ның яңа комплексын кертте.

Яңа комплекс иске комплекстагы җитешсезлекләрне бетерә. Аның байтак өстенлекләре һәм үзенчәлекләре бар. Физкультурага булган күтәренке таләпләрне тиз хәл итү белән алар физик тәрбиянең төгәл дәүләт системасын тәэмин итәләр. ГТО ның яңа комплексы өч баскычтан тора: БГТО, I нче һәм II нче баскыч ГТО.

БГТО 14—16 яштәге яшь үсмерләрне чолгап ала. Ул балалар организмының дөрес төзелүенә булышлык итүне күздә тота һәм мәктәптә укучы яшь үсмерләрнең 16 яштә БГТО значогы алуга ирешүләрен, ә мәктәпне тәмам иткән вакытта, 17—18 яшьләрдә, ГТО ның I нче баскычына нормалар тапшыруга ирешүләрен төп бурыч итеп куя. Оборонага хәзерләүнең бу системасы гомуми мәҗбүри хәрби хезмәт турындагы законга тулысынча туры килә.

Социалистик дәүләтебезнең чәчәк атуы аркасында, хезмәт ияләренең тормышлары торган саен яхшыра баруы балалар организмының нык һәм таза булып үсүе өчен уңайлы шартлар тудыра. 17 яштән ГТО ның I нче баскычына, ә 18 яштән—II нче баскычына нормалар тапшыру билгеләнде.

Яңа комплексның аермасы шунда, нормалар тапшыру ике өлешкә: һәр тапшыручы өчен мәҗбүри нормаларга һәм сайлап алып тапшыру нормаларына бүленә.

БГТО буенча 6 мәҗбүри норма, ә ГТО ның I нче һәм II нче баскычлары буенча 8 әр мәҗбүри норма билгеләнде. Сайлап алу буенча үткәрелә торган өлештә, мораль - ныклык сыйфатларын һәм физик сыйфатларны яхшыртудагы әһәмиятләренә карап, төрле физик упражнениеләр берләштерелгән. Яңа комплексның искесеннән зур өстенлеге группалардагы физик упражнениеләрнең күп төрле булуында, алардан үзең теләгән төрләрне сайлап алырга һәм һәрбер группадан берәр норма тапшырырга зур мөмкинлек бирелүендә. БГТО да сайлап алына торган группалар 5 булып, аларга 27 төрле физик упражнение керә. Сайлап алына торган группалар ГТО ның I нче баскычында 6, II нче баскычта 7 булып, аларга 60 төрле физик һәм спорт упражнениесе керә.

Тапшырылырга тиешле нормалар киметелде, ләкин һәр яктан физик хәзерлеккә булган таләп кимемәде.

Яңа комплекста практик хәрби упражнениеләргә, гимнастикага, автомото-спортка, авыр атлетикага зур урын бирелә.

БГТО да һәм ГТО да „тапшырылды" һәм „отлично" дигән аерым бәяләр бирелүе физик хәзерлекнең сыйфатын күтәрүгә ярдәм итә.

ГТО ның яңа комплексының мәҗбүри өлешенә физкультура оешмасын һәм физкультура хәрәкәте бурычларын, гигиенаның һәм үзеңә контроль ясауның нигезләрен белү керә.

Яңа комплексның барлык бу төп өстенлекләре физкультурникларның барсына да зур таләпләр куялар, шулай ук барлык физкультура оешмаларының эшләренә карата таләпне күтәрәләр.

Спорт-өйрәнү эшләренә, хезмәт ияләре массасының ГТО комплексы буенча системалы рәвештә шөгылләнүенә төп игтибар бирелергә тиеш.

Комсомол активы барлык яшьләргә үрнәк күрсәтергә, яңа комплексны беренче булып үзләштерергә һәм 1940 нчы елда ГТО буенча дәүләт заданиеләрен үтәүдә физкультура оешмаларына практик булышлык күрсәтергә тиеш.

Яңа комплексның әһәмиятен аңлату—физкультура комитетларының һәм партия, комсомол, совет, профсоюз оешмаларының әһәмиятле бурычы. Бу комплексның төзелеше, эчтәлеге нәрсәдән торуын һәм аның өстенлекләрен физкультурникларга һәм хезмәт ияләренең киң катлауларына тиз арада аңлатырга кирәк.

Татарстанда ГТО ның яңа комплексын кертү буенча зур гына эшләр үткәрелә. Күп кенә ирекле спорт оешмаларында, мәсәлән, „Большевик", „Буревестник", „Пламя", „Спартак" һәм башкаларда яңа комплекс җыелышларда өйрәнелде. Зеленодольский шәһәрендә яшьләр активының 800 кеше катнашкан җыелышында яңа комплекс турында доклад тыңлаганнан соң спорт җәмгыяте вәкилләре физкультура эшенең конкрет участкылары буенча социалистик йөкләмәләр алдылар. Физкультура һәм спорт эшләре буенча республика комитеты ГТО ның яңа комплексы буенча кыска сроклы семинарлар үткәрде. Семинарларда 35 район уполномоченные, Казандагы 42 физкультура инструкторы һәм урта мәктәпләрдәге 18 физкультура укытучысы булды.

Бу өлкәдә яңа китаплар кирәклеге нык сизелә. Яңа комплекс буенча татар телендә таблицалар һәм башка кирәкле материаллар басып чыгарырга кирәк.

Яңа комплекс—физкультура хәрәкәтен үзгәртеп корууда әһәмиятле этап. Хезмәтнең югары җитештерүчәнлеген бирүгә, сөекле Ватаныбызның чикләрен дошманнардан саклауга һәр вакыт хәзер торучы гражданнарны тәрбияләүгә бөтен көчне бирергә кирәк. **Д. Федотов.**

„Буревестник" спорт җәмгыяте ГТО ның яңа комплексы буенча чаңгычыларның Бөтенсоюз ярышына хәзерләнә. РӘСЕМДӘ: Спорт җәмгыяте члены иптәш Штуцер граната ыргыта. Б. Невзоров фотосы.

БЕЛДЕРҮЛӘР

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты шушы ел 10 нчы февраль, кич 6 сәгаттә, Кызыл Армия йортында, Казан шәһәре предприятиеләренең пар—энергия хуҗалыкларында, электростанцияләрдә һәм электр челтәрендә эшләүче стахановчыларның һәм энергетикларның шәһәр күләмендә җыелышын чакыра.

Көн тәртибе: 1 нче һәм 2 нче номер елылык—энергия станцияләренең 1939 нчы елдагы эшләренең йомгаклары һәм 1940 нчы елда бурычлары. Докладчылар: Энергокомбинат управляющие иптәш Никитин һәм 2 нче номер ТЭЦ управляющие иптәш **Коваленко.**

ВКП(б) ның Бауман район комитеты, сөйләшү өчен, эш сәгатьләрендә түбәндәге иптәшләрнең килүләрен сорый:

Григорий Евгеньевич Ананьев—элек Сантехмонтаж конторасында эшләгән. Прокофий Михайлович Харитонов—элек ВЛКСМ ның Өлкә Комитетында эшләгән. Михаил Васильевич Хрисанфов—элек ашханәләр трестында эшләгән.

Югарыда фамилияләре күрсәтелгән иптәшләрнең эшләү яисә тору урыннарын белүчеләрдән,—ул турыда ВКП(б) ның Бауман район комитетының оештыру—инструкторлык бүлегенә белдерүләре сорала.

Җаваплы редактор
һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

БҮГЕН ТЕАТР ҺӘМ КИНОЛАРДА:

Татар Дәүләт Академия театры—Булак арты „республикасы". Талон 12.

Зур театр—Маскарад. Талон 95.

Дәүләт циркы—Москва 4 нче труппасының соңгы гастроле һәм М. Золло.

„Электро"—Футлярдагы кеше. „Унион—Минин һәм Пожарский, „Кызыл Йолдыз"—Ерак Көнчыгышта. „Чаткы"—Пэпо. „Пионер"—көндез һәм кич Патриот. „Колхозник"—Партия билеты. „Рот-Фронт"—Бөек гражданин (2 нче сериясе). Хезмәт Сарае—Һава почтасы.

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 239 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 503.